ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

27.02.2019 **Чистай шәһәре** № 100

Татарстан Республикасы Чистай
муниципаль районында ”Балаларны мәктәпкәчә
белем бирүнең (балалар бакчалары) төп
гомуми белем бирү программасын тормышка
ашыручы белем бирү оешмаларына исәпкә
кую һәм кабул итү” буенча муниципаль
хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау
турында”

29.12.2012 елда кабул ителгән “Россия Федерациясендә белем бирү турында”гы 273нче Федераль закон, 27.07.2010 елгы “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы 210 нчы номерлы Федераль закон нигезендә,Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгының 10.03.2015 елгы ”Балаларны мәктәпкәчә белем бирүнең (балалар бакчалары) төп
гомуми белем бирү программасын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларына исәпкә кую һәм кабул итү” буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының үрнәк формасын раслау турында”гы 1389/15нче Боерыгы белән Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында ”Балаларны мәктәпкәчә белем бирүнең (балалар бакчалары) төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларына исәпкә кую һәм кабул итү” буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитетының 22.06.2018 елгы 471 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында ”Балаларны мәктәпкәчә белем бирүнең (балалар бакчалары) төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларына исәпкә кую һәм кабул итү” буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты” яңа редакциядә” дигән карары үз көчен югалткан дип табарга.

3.”Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф идарәсе” МКУнә (О.В. Купцова) әлеге карарны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында: http://chistopol.tatarstan.ru/ һәм хокукый-мәгълүматның рәсми интернет-порталында: http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштырырга.

4. Әлеге карарны үтәүгә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Г.Ю. Задворновага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
башкарма комитеты
карарына кушымта
________________________

**Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында**
**”Балаларны мәктәпкәчә белем бирүнең (балалар бакчалары) төп гомуми**

**белем бирү программасын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларына исәпкә кую һәм кабул итү” буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең АДМИНИСТРАТИВ РЕГЛАМЕНТЫ**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. ТР Чистай муниципаль районында ”Балаларны мәктәпкәчә белем бирүнең (балалар бакчалары) төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларына исәпкә кую һәм кабул итү” буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (алга таба - Административ регламент) Чистай муниципаль районында мәктәпкәчә яшьтәге балаларны төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларына исәпкә кую һәм кабул итү тәртибен билгели (алга таба – муниципаль хезмәт).

1.2. Муниципаль хезмәт алучылар булып Россия Федерациясе гражданнары, ТР Чистай муниципаль районы территориясендә яшәүче 2 яшьтән 7 яшькә кадәрге балалары булган ата-аналар (башка законлы вәкилләр) чит илләр гражданнары торалар.

Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыручы **белем бирү оешмаларына чираттан тыш урнаштыру хокукына ия булучылар** (алга таба – Оешма)**:**

- судьялар балалары;
- прокурорлар һәм Тикшерү комитеты хезмәткәрләре балалары;
- Чернобыль АЭСындагы фаҗига нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә эләккән гражданнарың һәм аларга тигезләштерелгән категориядәге гражданнар балалары;
- террористик оешмаларның һәм төркемнәрнең эшчәнлеген ачыклау һәм кисәтү буенча махсус көчләрнең, Россия Федерациясенең Төньяк-Кавказ төбәге территориясендә контртеррористик операцияләр үткәрү буенча гаскәрләрнең (көчләрнең) берләшкән группировкаларының һәлак булган (хәбәрсез югалган), үлгән, инвалид булган хезмәткәрләренең һәм хәрби хезмәткәрләренең балалары;
-эчке эшләр органнары, дәүләт янгынга каршы хезмәте, җинаять-үтәү системасы, турыдан-туры Дагестан Республикасы территориясендә терроризмга каршы көрәштә катнашучылар һәм хәрби вазифаларын үтәгәндә һәлак булган (хәбәрсез югалган), үлгән, инвалид булган хәрби хезмәткәрләр һәм хезмәткәрләр балалары”;

**Оешмага чираттан тыш урнаштыру хокукына ия булучылар:**

- инвалид балалар һәм ата-аналарының берсе инвалид булган балалар;
- күп балалы гаиләләр балалары;
- полиция хезмәткәрләре балалары, шул исәптән хезмәт вазифаларын үтәгәндә имгәнү нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) яки сәламәтлегенә башка төрле зыян килгән полиция хезмәткәрләре балалары; полициядә хезмәт итү чорында алган авыру нәтиҗәсендә үлгән полиция хезмәткәре балалары; хезмәт вазифаларын үтәгәндә имгәнү яки сәламәтлегенә башка төрле зыян килү нәтиҗәсендә полициядә хезмәт итүдән азат ителгән һәм киләчәктә полициядә хезмәт итү мөмкинлеге булмаган Россия Федерациясе гражданины балалары; хезмәт вазифаларын үтәгәндә имгәнү яки сәламәтлегенә башка төрле зыян килү нәтиҗәсендә яисә полициядә хезмәт итү чорында алган авыру нәтиҗәсендә киләчәктә полициядә хезмәт итү

мөмкинлеге булмау сәбәпле, полициядә хезмәт итүдән азат ителгәннән соң бер ел барышында үлгән Россия Федерациясе гражданины балалары; Россия Федерациясе гражданины, полиция хезмәткәре тәрбиясендәге (тәрбиясендә булган) балалар;
- хәрби хезмәткәрләр балалары;
- махсус исемнәре булган һәм җинаять-үтәү системасы учреждениеләрендә һәм органнарында, Дәүләт янгынга каршы хезмәтнең федераль янгынга каршы хезмәтендә, наркотик һәм психотроп матдәләр әйләнешенә контроль буенча органнарда, Россия Федерациясенең таможня органнарында, шул исәптән хезмәт вазифаларын үтәгәндә имгәнү нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) яки сәламәтлегенә башка төрле зыян килгән; хезмәт итү чорында алган авырулар нәтиҗәсендә үлгән; хезмәт вазифаларын үтәгәндә имгәнү яки сәламәтлегенә башка төрле зыян килү һәм киләчәктә полициядә хезмәт итү мөмкинлеге булмау сәбәпле, хезмәттән азат ителгән; хезмәт вазифаларын үтәгәндә имгәнү яки сәламәтлегенә башка төрле зыян килү нәтиҗәсендә яисә полициядә хезмәт итү чорында алган авыру нәтиҗәсендә киләчәктә полициядә хезмәт итү мөмкинлеге булмау сәбәпле, полициядә хезмәт итүдән азат ителгәннән соң бер ел барышында үлгән хезмәткәрләрнең балалары; Россия Федерациясе гражданины, полиция хезмәткәре тәрбиясендәге (тәрбиясендә булган) балалар;”

ТР Чистай муниципаль районы территориясендә үз акчалары хисабына өстәмә мәктәпкәчә урыннар булдырган оешмалар хезмәткәрләре балалары мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында урыннар белән гамәлдәге закон нигезендә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы катнашында төзелгән дәүләт-шәхси партнерлык турындагы килешү шартлары нигезендә булдырылган урыннар белән бертигез дәрәҗәдә тәэмин ителәләр.

Оешмага игезәк балаларның берсе җибәрелгәндә аларның икенчесе (аннан соңгысы) әлеге Оешмага чираттан тыш тәртиптә җибәрелә.

Федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм законлы норматив-хокукый актлар белән каралмаган башка нигезләр буенча ташлама бирү рөхсәт ителми.

1.3. Муниципаль хезмәт ”Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф идарәсе” МКУсе (алга таба –Мәгариф идарәсе) һәм әлеге Административ регламентның 1нче кушымтасында күрсәтелгән оешмалар тарафыннан күрсәтелә.

1.4. Мәгариф идарәсенең урнашу урыны: ТР, Чистай шәһәре, К.Маркс урамы, 21нче йорт.

Эш графигы: дүшәмбе - җомга 8.00 - 17.00кә кадәр (төшке ял 12.00- 13.00).

1.5. Мәгариф идарәсенең белешмә өчен телефоннары: 5-10-41 - сәркатип; 5-17-75 – мәктәпкәчә тәрбия буенча белгечләр.

1.6. Мәгариф идарәсенең Интернет челтәрендәге рәсми сайты адресы: https://edu.tatar.ru/chistopol/roo.

1.7. Оешманың урнашу урыны, эш графигы, белешмә өчен телефоннар, рәсми сайты адреслары турындагы мәгълүмат 1нче Кушымтада күрсәтелгән.

1.8. Муниципаль хезмәт турында мәгълүмат алу мөмкинлекләре:
- гариза бирүчеләр белән эшләү өчен биналарда урнашкан муниципаль хезмәтләр турындагы визуаль һәм текст мәгълүматларыннан торган мәгълүмати стендлар чаралары буенча;

- Мәгариф идарәсенең рәсми сайтында;

- Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында: https://uslugi.tatar.ru/cei/feedback тәкъдим ителгән кире элемтә формасы аша һәм техник ярдәм күрсәтү хезмәте телефоны буенча: (8(843)5-114-115);

- Мәгариф идарәсенә һәм Оешмага телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон буенча);

- язмача мөрәҗәгать иткәндә Мәгариф идарәсендә.

1.9.Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге норматив-хокукый актлар белән гамәлгә ашырыла: Россия Федерациясе Конституциясе ("Российская газета", N 7, 21.01.2009);

29.12.2012 елда кабул ителгән “Россия Федерациясендә белем бирү турында”гы 273нче Федераль закон ("Российская газета", N 303, 31.12.2012.);

24.07.1998 елда кабул ителгән «Россия Федерациясендә бала хокукының төп гарантияләре турында”гы 124нче Федераль закон ("Российская газета", N 147, 05.08.1998);

06.10.2003 елда кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 131нче номерлы Федераль закон ("Российская газета", N 202, 08.10.2003); .

02.05.2006 елда кабул ителгән “Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатен карау тәртибе турында”гы 59нчы Федераль закон ("Российская газета", N 95, 05.05.2006);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 17.12.2009 елда кабул ителгән “Электрон формада күрсәтелә торган беренче чираттагы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең җыелма исемлеген раслау турында”гы 1993-р Боерыгы ("Российская газета", N 247, 23.12.2009);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 25 апрелендә кабул ителгән “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестрына кертелергә тиешле дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр һәм дәүләт йөкләмәсе (заказы) яки муниципаль йөкләмә (заказ) урнашкан башка оешмалар тарафыннан күрсәтелә һәм электрон формада күрсәтелүче хезмәтләр исемлеген раслау турында”гы 729-р Боерыгы ("Российская газета", N 93, 29.04.2011);

27.07.2010 елда кабул ителгән “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы 210нчы номерлы Федераль закон ("Российская газета", N 168, 30.07.2010);

РФ Президентының 02.10.1992 елгы “Инвалидларны дәүләт яклавының өстәмә чаралары турында”гы 1157 нче Фәрманы ("РФ Президентының һәм Хөкүмәтенең актлар җыентыгы”, 05.10.1992, N 14,1098нче маддә);

РФ Президентының 05.05.1992 елгы “Күп балалы гаиләләрне социаль яклау буенча чаралар турында”гы 431нче Фәрманы ("Ведомости СНД и ВС РФ", 14.05.1992, N 19, 1044нче маддә);

07.02.2011 елда кабул ителгән “Полиция турында”гы 3нче Федераль закон ("Российская газета", N 25, 08.02.2011);

27.05.1998 елда кабул ителгән “Хәрби хезмәткәрләрнең статусы турында”гы 76 нчы Федераль закон ("Российская газета", N 104, 02.06.1998);

17.01.1992 елда кабул ителгән “Россия Федерациясе Прокуратурасы турында”гы 2202-1нче Федераль Закон ("Российская газета", N 39, 18.02.1992);

Россия Федерациясенең 26.06.1992 елда кабул ителгән “Россия Федерациясендә судьялар статусы турында”гы 3132-1нче Законы ("Российская газета", N 170, 29.07.1992);

Россия Федерациясенең 15.05.1991 елда кабул ителгән “Чернобыль АЭСындагы фаҗига нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарны социаль яклау турында”гы 1244-1нче Законы ("Ведомости СНД и ВС РСФСР", 1991, N 21, 699нчы маддә);

РФ Президентының 05.06.2003 елгы “Наркотикларның һәм психотроп матдәләрнең әйләнешен контрольдә тоту буенча органнарда хокук саклау хезмәте турында”гы 613нче Фәрманы ("Российская газета", N 112, 11.06.2003);

ТРның 1.08.2011 елда кабул иткән “Татарстан Республикасында дәүләт-шәхси партнерлык турында”гы 50нче Законы (“Республика Татарстан”, № 156, 05.08.2011 ел.);

21.12.1994 елда кабул ителгән “Янгын куркынычсызлыгы турында”гы 69нчы Федераль закон (“Российская газета”, №3, 05.01.1995 ел);

30.12.2012 елда кабул ителгән “Башкарма властьның кайбер федераль органнары хезмәткәрләренә социаль гарантияләр һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”гы 283 нче Федераль закон ("Российская газета", № 3, 11.01.2013);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2004 елның 9 февралендә кабул ителгән

"Башкарма властьның федераль органнарының контртеррористик операцияләрдә катнашкан һәм Россия Федерациясенең Төньяк-Кавказ төбәге территориясендә хокук тәртибен һәм җәмәгать иминлеген тәэмин иткән хезмәткәрләренә һәм хәрби хезмәткәрләренә өстәмә гарантияләр һәм компенсацияләр турында”гы 65 нче Карары (“Российская газета”, №28, 13.02.2004 ел.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1999 елның 25 августында кабул ителгән “Эчке эшләр органнары, Дәүләт янгынга каршы хезмәте, җинаять-үтәү системасы, турыдан-туры Дагестан Республикасы территориясендә терроризмга каршы көрәштә катнашкан һәм хәрби вазифаларын үтәгәндә һәлак булган (хәбәрсез югалган), үлгән, хезмәт вазифаларын үтәү сәбәпле инвалид булган хәрби хезмәткәрләрнең һәм хезмәткәрләрнең гаилә әгъзаларын социаль яклау буенча өстәмә чаралар турында”гы 936 нчы карары (“Российская газета”, №169, 31.08.1999 ел.);

Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 елның 30 августында кабул иткән “ Төп гомумбелем программалары – мәктәпкәчә белем бирүнең белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру Тәртибен раслау турында”гы 1014нче Боерыгы ("Российская газета", N 238, 23.10.2013);

Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2015елның 28 декабрендә кабул ителгән”Укучыларны мәктәпкәчә белем бирүнең белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы бер оешмадан тиешле дәрәҗәдәге һәм юнәлештәге белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген тормышка ашыручы башка оешмаларга күчерүне тормышка ашыру Тәртибен һәм шартларын раслау турында”гы 1527нче Боерыгы (“Российская газета”, № 6895, 10.02.2016);

Татарстан Республикасы “Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставы (Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының 29.01.2014 елгы 32/1 нче карары белән расланган).

## II. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Стандартка таләпләр исеме | Стандартка таләпләр эчтәлеге | Муниципаль хезмәтне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1.Муниципаль хезмәт исеме | Балаларны мәктәпкәчә белем бирүнең (балалар бакчалары) төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларына исәпкә кую һәм кабул итү. | Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 елның 30 августында кабул иткән “Төп гомумбелем программалары– мәктәпкәчә белем бирүнең белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру Тәртибен раслау турында”гы 1014нче Боерыгы |
| 2.2.Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче башкарма власть органы исеме | Муниципаль хезмәт “ТР Чистай муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф идарәсе” МКУсе һәм әлеге Административ регламентның 1нче кушымтасында күрсәтелгән белем бирү оешмалары тарафыннан күрсәтелә. Муниципаль хезмәт күрсәткән өчен җаваплы вазифаи затлар булып ТР Чистай муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф идарәсе” МКУсе хезмәткәрләре торалар ( алга таба - вәкаләтле хезмәткәр) | 29.12.2012 елда кабул ителгән “Россия Федерациясендә белем бирү турында”гы 273нче Федераль закон |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып баланы мәктәпкәчә белем бирүнең (балалар бакчасы) төп гомуми белем бирү программасын | Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 елның 30 августында кабул иткән “ Төп |

| | | |
|---|---|---|
| | тормышка ашыручы белем бирү оешмасына кабул итү тора. | гомумбелем программалары – мәктәпкәчә белем бирүнең белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру Тәртибен раслау турында”гы 1014нче Боерыгы |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы | - исәпкә кую өлешендә муниципаль хезмәт күрсәтү дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында гаризаны тутыру яки “ТР Чистай муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф идарәсе” МКУсенә шәхсән кәгазьгә язылган гариза биргән вакыттан гамәлгә ашырыла<br>- балаларны Оешмага кабул итү өлешендә – 4 айга кадәр срокта гариза бирүчегә Оешмага җибәрү турында хәбәр иткәннән соң | - |
| 2.5.Исәпкә кую өчен гариза тутырганда кирәкле белешмәләр исемлеге | - баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме;<br>- баланың туган көне;<br>-туу турындагы таныклык мәгълүматлары;<br>- фактта яшәү урыны (адресы);<br>- әнисенең, әтисенең яки законлы вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме, электрон почта адресы, телефон номеры;<br>-әти-әнисенең (законлы вәкиленең) шәхесен раслаучы документ мәгълүматлары;<br>- баланы белем бирү оешмасына кабул итү буенча ташламаның булу-булмавына белешмә;<br>-баланың сәламәтлеге буенча ихтыяҗы;<br>- теләк буенча бер оешма;<br>-төркемдә тәрбияләргә һәм укытырга теләгән тел;<br>- баланы Оешмага кабул итү датасы; | - |

| | | |
|---|---|---|
| | - үзең теләгән Оешмада урын булмаганда тәкъдим ителгән башка балалар бакчасына ризалашу/ризалашмау | |
| 2.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив-хокукый актлар нигезендә кирәк булган документларның тулы исемлеге, алар дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында һәм аларны гариза бирүче тәкъдим итәргә хаклы. | Баланың туу турындагы таныклыгы;<br><br>Ташламаларны раслаучы документлар:<br>күп балалы гаилә балалары;<br>Чернобыль АЭСындагы фаҗига нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә эләккән гражданнарның балалары;<br>инвалид-балалар;<br>ата-анасының берсе инвалид булган гаиләләр. | |
| 2.7.Оешмага кабул итү өчен кирәкле документлар исемлеге | - Оешма җитәкчесе исеменә әти-әнисенең (законлы вәкиленең) язмача гаризасы;<br>- билгеләнгән үрнәктәге медицина белешмәсе;<br>- баланың әти-әнисенең (законлы вәкиленең) берсенең шәхесен раслаучы документ;<br>- психологик-медик-педагогик комиссия нәтиҗәсе (баланы компенсацияләүче һәм катнаш юнәлештәге төркемгә кабул иткәндә) | Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 елның 30 августында кабул иткән “ Төп гомумбелем программалары – мәктәпкәчә белем бирүнең белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру Тәртибен раслау турында”гы 1014нче Боерыгы |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул итүдән баш тарту өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге | исәпкә кую өлешендә:<br>- баланың яше Оешмага кабул ителә торган максималь яшьтән артып китү;<br>Оешмага кабул итү өлешендә:<br>-“Электрон балалар бакчасы” системасында баланы Оешмага җибәрү турында мәгълүмат булмау. | 29.12.2012 елда кабул ителгән “Россия Федерациясендә белем бирү турында”гы 273нче Федераль закон |
| Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш | 1) исәпкә кую өлешендә:<br>- баланың туу турындагы | 29.12.2012 елда кабул ителгән “Россия |

| | | |
|---|---|---|
| тарту өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге | таныклыгы мәгълүматларын идентификацияләүгә комачаулаучы дөрес булмаган (җитәрлек түгел) белешмә бирү;<br>- превышение возраста ребенка максимального возраста детей, принимаемых в Организацию;<br>- үзең теләгән Оешмадагы тәрбияләү һәм укыту теленең үзең теләгән тәрбияләү һәм укыту телен ә туры килмәве;<br>2) Оешмага кабул итү өлешендә:<br>-"Электрон балалар бакчасы" системасында баланы Оешмага җибәрү турында мәгълүмат булмау;<br>- баланың Оешмага йөрүенә медицина буенча күрсәткечләрнең каршы булу;<br>- әти-әнисенең (законлы вәкиленең) муниципаль хезмәт алудан баш тартуы турында гариза. | Федерациясендә белем бирү турында"гы 273нче Федераль закон;<br><br>Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 елның 30 августында кабул иткән "Төп гомумбелем программалары – мәктәпкәчә белем бирүнең белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру Тәртибен раслау турында"гы 1014нче Боерыгы |
| 2.9.Муниципаль хезмәтләр күрсәткән өчен алына торган түләүләр тәртибе, күләме һәм сәбәбе . | Муниципаль хезмәт бушлай нигездә күрсәтелә. | 29.12.2012 елда кабул ителгән "Россия Федерациясендә белем бирү турында"гы 273нче Федераль закон |
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы сорауны биргән һәм шундый хезмәт нәтиҗәсен алган вакытта чиратта торуның максималь срогы | Чиратта шәхсән кабул итү вакытын көтү 15 минуттан артмаска тиеш. Әгәр хезмәт пенсионерларга, инвалидларга күрсәтелсә, икенче гариза бирүченең көтү (хезмәт күрсәтү) срогы 30 минутка кадәр арттырылырга мөмкин.<br>Мөрәҗәгать итүчеләрнең барысын да кабул итү эш көне тәмамланырга 1 сәгать кала тәэмин ителергә тиеш. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.11. Гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы соравын теркәү срогы, шул исәптән электрон формада | Гариза бирүче “ТР Чистай муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф идарәсе” МКУсенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә исәпкә кую турындагы гаризаны теркәү Административ регламентның III бүлеге белән каралган тәртиптә гариза бирүче мөрәҗәгать иткән вакыттан алып 1 эш көне дәвамында.<br>Баланы Оешмага кабул итү турындагы гаризаны теркәү Административ регламентның III бүлеге белән каралган тәртиптә гариза бирүче мөрәҗәгать иткән вакыттан алып 1 эш көне дәвамында. | |
| 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга таләпләр | Гариза бирүчеләр белән эшләү өчен биналарда муниципаль хезмәт турында мәгълүмат стендлары урнаштырыла, анда муниципаль хезмәт турында текстлы һәм визуаль эчтәлектәге мәгълүмат була. Бинаның фасад өлешендә мәгариф идарәсенең муниципаль органы исеме турында мәгълүмат урнаштырыла.<br>Кабул итүне көтүче гариза бирүчеләргә документларны тутыру өчен урындыклар, өстәлләр куелган урын бирелә.<br>Бина санитар кагыйдәләр һәм нормалар нигезендә җиһазландырылган булырга тиеш.<br>Инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтү урынына каршылыксыз керүләре, шул исәптән объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү урынына керүләре вакытында объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итүләре тәэмин ителә. Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турындагы | 27.07.2010 елда кабул ителгән “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы 210нчы номерлы Федераль закон |

| | | |
|---|---|---|
| | визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла. | |
| 2.13.Муниципаль хезмәтләрне алу мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре | Муниципаль хезмәт күрсәтү мөмкинлеге күрсәткечләре булып торалар:<br>бинаның җәмәгать транспорты йөри торган урында урнашуы;<br>белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итүне гамәлгә ашыручы биналарның җитәрлек күләмдә булуы;<br>мәгълүмат стендларында, Интернет челтәрендә, министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, сроклары турында тулы мәгълүмат булу;<br>инвалидлар өчен закон тарафыннан каралган мөмкинлек шартлары булу.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты характерлана:<br>документларны кабул итү һәм карау срокларының үтәлүе;<br>муниципаль хезмәт нәтиҗәсе алу срогының үтәлүе;<br>муниципаль хезмәт күрсәткән өчен җаваплы затлар тарафыннан кылынган муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын бозуга прецедентлар (нигезләнгән шикаятьләр) булу. | 27.07.2010 елда кабул ителгән “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы 210нчы номерлы Федераль закон |
| 2.14. Муниципаль хезмәтне электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Электрон төрдә муниципаль хезмәт күрсәтү Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында: (https://uslugi.tatar.ru) тормышка ашырыла. | 27.07.2010 елда кабул ителгән “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы 210нчы номерлы Федераль закон |

## III. Административ процедуралар

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеген тасвирлау

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү үз эченә түбәндәге административ процедураларны ала:

- исәпкә кую (“Электрон балалар бакчасы” (алга таба – Система) автоматлаштырылган мәгълүмат системасында теркәлү, исәпкә кую өчен гариза);

-Оешмага җибәрү;

- Оешмага кабул итү.

3.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең блок-схемасы 3нче кушымтада тәкъдим ителгән.

3.3. Исәпкә кую.

3.3.1. Ата-аналар (законлы вәкилләр) тарафыннан Оешмага урнаштыру буенча исәпкә кую өчен гариза тутыру гамәлгә ашырыла:

- Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша (https://uslugi.tatar.ru/);

- Бердәм дәүләт хезмәтләре порталы аша (https://beta.gosuslugi.ru/ );

- Мәгариф идарәсенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә. Системада гариза кабул итү һәм аны теркәү ел дәвамында тормышка ашырыла.

Мәгариф идарәсенә мөрәҗәгать иткәндә Системага гариза мәгълүматларын кертүне Мәгариф идарәсе боерыгы белән билгеләнгән вәкаләтле хезмәткәр тормышка ашыра.

Гаризаны тутырганда ата-аналар (заонлы вәкилләр) персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирәләр (Административ регламентка 2нче кушымта).

3.3.2. Исәпкә кую өчен гариза биргәндә Система тарафыннан кертелгән туу турындагы таныклык мәгълүматларының дөреслеген тикшерү гамәлгә ашырыла. Әгәр мәгълүматлар дөрес булмаса яисә бөтенләй булмаса Системада гаризага “Расланган документлар” статусы бирелә. Әлеге очракта гариза бирүчегә документларны раслау өчен кабул итү сәгатьләрендә Мәгариф идарәсенә барырга кирәк. Гариза бирүче документларны раслаганнан соң, вәкаләтле хезмәткәр документларны раслаган көннән соң 1 эш көне дәвамында Системада гаризага “Теркәлгән” статусы бирә (гаризаны биргән көннән).

3.3.3.Гаризаны законлы вәкил (опекун, попечитель) биргәндә, гариза системада “Опека (попечитель) раслаган” статусы ала. Әлеге очракта гариза бирүчегә опека (попечитель) турында документларны раслау өчен Мәгариф идарәсенә барырга кирәк. Гариза бирүче документларны раслаганнан соң, вәкаләтле хезмәткәр документларны раслаган көннән соң 1 эш көне дәвамында гаризага “Теркәлгән” статусы бирә (гаризаны биргән көннән).

3.3.4. Әгәр гариза бирүченең Оешмага чираттан тыш, беренче чиратта кабул ителү хокукы булса, аның документларына “Документларныраслау” статусы бирелә. Гариза бирүчегә Мәгариф идарәсенә ташламаны раслаучы документның төп нөсхәсен, шулай ук аның күчермәсен тапшырырга кирәк, ташламаны раслаучы документлардан кала:

күп балалы гаиләләрдәге балалар;

Чернобыль АЭСындагы фаҗига нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарың балалары;

инвалид-балалар;

ата-анасының берсе инвалид булган гаиләләр.

Ташламаларның әлеге исемлеге Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталына бирелгән гаризалар буенча район мәгариф бүлегенә ташламаларны раслату өчен шәхсән килеп йөрмәс өчен Татарстан Республикасының Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының “Татарстан Республикасы халкының социаль регистры” дәүләт мәгълүмат системасына сорау җибәрү ярдәмендә автомат рәвештә раслана.

Ташламаны раслаучы документ күчермәсе Мәгариф идарәсендә саклана.

Гариза бирүче документларны раслаганнан соң вәкаләтле хезмәткәр документларны раслаган көннән соң 1 эш көне дәвамында гаризага “Теркәлгән” статусы бирә (гаризаны биргән көннән).

Әгәр гариза бирүчедән ташлама булуын раслау гына кирәк булса, гариза Системада гомуми нигезләрдә ташламаны раслаганчы теркәлә.

Ташламаның билгеләнгән гамәлдә булу срогы чыкканнан соң Гариза бирүчегә Оешмага чираттан тыш яки беренче чиратта кабул итү хокукын расларга кирәк.

3.3.5. Теркәлгән гаризага шәхси идентификацион номер бирелә. Гаризаның статусын һәм гариза бирүченең чираты нинди булуын Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы: https://uslugi.tatar.ru аша баланың туу турындагы таныклыгы мәгълүматлары буенча (сериясе һәм номеры) яки дәүләт хезмәтләренең бердәм порталы https://beta.gosuslugi.ru/ аша гаризаның шәхси идентификацион номеры буенча, шулай ук Мәгариф идарәсенә кабул итү сәгатьләрендә шәхсән яки телефон буенча мөрәҗәгать итеп тикшерергә мөмкин.

3.3.6. Исәпкә куйганда гариза бирүче баланы кабул итү өчен гаризасында бер Оешманы күрсәтергә хаклы.

3.3.7. Гаризага шәхси идентификацион номер бирелгәннән соң гариза бирүченең гаризасы буенча теләгән Оешманы алмаштыру рөхсәт ителә. Гариза бирүче үзе теләгән Оешма урнашу урыны буенча мәгариф идарәсенә үзе теләгән Оешмага алмашу турында гариза бирә. Бу очракта исәпкә кую көне саклана.

Шулай ук гариза бирүче үзе теләгән Оешманы дәүләт хезмәтләренең бердәм порталы https://beta.gosuslugi.ru/ аша бирелгән гаризада да үзгәртә ала.

3.3.8. Вәкаләтле хезмәткәрнең гражданинның гаризасына җибәрелгән хаталарны бетерү максатында (баланың фамилиясе, исеме, атасының исемендәге,

туу датасы, туу турындагы таныклыктагы реквизитлардагы һ.б., исәпкә кую датасыннан кала) гариза биргән көннән соң 5 эш көне эчендә кирәкле төзәтмәләр кертергә хокукы бар. Әлеге срок чыкканнан соң үзгәрешләрне вәкаләтле хезмәткәр соравы буенча Система администраторы кертә.

3.3.9.Гариза бирүченең исәпкә кую турындагы гаризасы, баласына 8 яшь тулган, вәкаләтле хезмәткәр тарафыннан "архив" статусына күчерелә.

3.3.10. Элек исәпкә куелган баланы буш урыннар булган авыл Оешмасына исәпкә кую һәм кабул итү рөхсәт ителә. Гариза авыл Оешмасының урнашу урыны буенча мәгариф идарәсе органына бирелә. Беренче гариза буенча үзең теләгән Оешмага чират саклана.

3.3.11.Яңа Оешмалар Системага вәкаләтле хезмәткәр гаризасы буенча Система администраторы тарафыннан кертелә.

3.4. Комплектлау .

3.4.2. Оешманы комплектлау башлануга 30 көн кала чираттагы уку елында (планлы төркемнәр) балаларның һәр яшь категориясе нигезендә төркемнәрдәге буш урыннар саны турындагы белешмәне Мәгариф идарәсенә раслауга тапшыралар.

3.4.3. Оешманы чираттагы уку елына комплектлау агымдагы елның 1 июненнән 31 августына кадәр чираттагы уку елына расланган төркемнәр саны һәм алардагы буш урыннар нигезендә гамәлгә ашырыла. Системада комплектлаган вакытта балаларның яше агымдагы елның 1 ноябренә кадәр исәпләнә.

Уку елы дәвамында буш урыннар булган очракта Оешманы тулысынча комплектлау Административ регламентның 3нче пункты белән каралган тәртип нигезендә үткәрелә.

3.4.4. Комплектлау нәтиҗәләре турында гражданнарга мәгълүмат бирү Мәгариф идарәсенең мәгълүмат стендларында мәгълүмат урнаштыру чарасы аша тормышка ашырыла.

3.4.5. Оешманы комплектлаганда гражданнарның гаризалары бер эш көне дәвамында гына вәкаләтле хезмәткәрләр тарафыннан эшкәртүдә була.

3.5. Оешмага җибәрү һәм кабул итү

3.5.1. Гариза бирүченең чираты җиткәндә һәм үзең теләгән Оешмада тиешле яшь төркемендә урын булганда гаризага "Мәктәпкәчә белем бирү оешмасына җибәрелде" дигән статус бирелә. Әлеге статусны бирү турындагы хәбәр Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында, дәүләт хезмәтләренең Бердәм порталында чагылдырыла.

3.5.2. Гариза бирүче "Мәктәпкәчә белем бирү оешмасына җибәрелде" дигән статус бирелгәннән соң 30 календарь көн эчендә баланы кабул итүне раслату өчен Оешмага килергә тиеш.

3.5.3. Оешма җитәкчесе гариза бирүче баланы кабул итү турындагы гариза белән мөрәҗәгать иткән көннән соң 1 эш көне дәвамында Системада гаризага "Килешү төзү" статусы бирә.

“Килешү төзү” статусы бирелгәннән соң  гариза бирүче   бер ай эчендә Оешмага килешү төзү өчен килергә тиеш.

3.5.4. Әгәр гариза бирүчене  бала җибәрелгән Оешма канәгатьләндермәсә, гариза бирүче тарафыннан  әлеге Оешмага җибәрүдән баш тарту  рәсмиләштерелә. Гаризага “теркәлгән” статусы бирелә. Бу очракта исәпкә кую датасы үзгәрми.

Тәкъдим ителгән  Оешмага җибәрүдән  баш тарту Мәгариф  идарәсенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә Мәгариф идарәсе билгеләгән формада  язмача рәсмиләштерелә.

3.5.5. Гариза бирүче “Мәктәпкәчә белем бирү оешмасына җибәрелде” дигән статус  бирелгәннән соң  Административ регламентның 3.5.2. пунктында билгеләнгән срокта  Оешмага килмәсә,  гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү туктатыла.  Системада гаризага “Килмәде” статусы бирелә.

3.5.6. Әгәр гариза бирүче  хезмәт алуга үз теләген расласа,  гаризага “Теркәлде” статусы бирелә. Бу очракта исәпкә кую датасы үзгәрми.  Әгәр гариза бирүче муниципаль хезмәт алудан баш тартса, гаризага  “ Хезмәт күрсәтү кире кагылды” статусы бирелә.  Муниципаль хезмәт алуны раслау яки баш тарту яшәү урыны буенча Мәгариф  идарәсенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә Мәгариф идарәсе билгеләгән формада  язмача рәсмиләштерелә. Раслаганда теләгән кабул итү датасы гариза бирүче  муниципаль хезмәт алу ихтыяҗын раслап мөрәҗәгать  иткән көннән соңгы датага алмаштырыла.

3.5.7. Ата-аналар (законлы вәкилләр)     белән килешү төзегәннән соң Оешма җитәкчесе 1 эш көне дәвамында Системага  килешү реквизитларын кертә һәм Системада гаризага “Мәктәпкәчә белем бирү оешмасына кабул ителде” статусы бирелә.

Баланы караган һәм тәрбияләгән  өчен  ата-аналар түләве “Мәктәпкәчә белем бирү оешмасына кабул ителде” статусы бирелгән көннән билгеләнә.

3.5.8. Гариза бирүче килешү төзү өчен билгеләнгән срокта килмәсә Оешма җитәкчесе гаризага “Килмәде” статусы бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар “Килешү төзү” статусы бирелгән көннән бер ай үткәннән соң 1 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

3.5.9. Әгәр гариза бирүче  хезмәт алуга үз теләген расласа,  гаризага “Теркәлде” статусы бирелә. Бу очракта исәпкә кую датасы үзгәрми. Раслаганда теләгән кабул итү датасы  гариза бирүче  муниципаль хезмәт алу ихтыяҗын раслап мөрәҗәгать иткән көннән соңгы датага алмаштырыла.

Әгәр гариза бирүче  муниципаль хезмәт алудан баш тартса, гаризага  “ Хезмәт күрсәтү кире кагылды” статусы бирелә.  Муниципаль хезмәт алуны раслау яки баш тарту яшәү урыны буенча Мәгариф  идарәсенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә Мәгариф идарәсе билгеләгән формада  язмача рәсмиләштерелә.

3.5.10. Сәламәтләндерү  юнәлешендәге төркемнәргә гаризада сәламәтлек буенча ихтыяҗ күрсәтелгән  балалар җибәрелә.

Баланы сәламәтләндерү юнәлешендәге төркемгә билгеле бер вакытка (вакытлыча, медицина нәтиҗәсе яки психологик-медик-педагогик комиссия нәтиҗәсе нигезендә) җибәргәндә юлламада “вакытлыча кабул ителә” билгесе куела.

Гариза чиратта исәпкә куюның беренче датасы белән саклана.

Әгәр сәламәтләндерү юнәлешендәге төркемгә җибәрү вакытына кадәр бала башка Оешмага йөрегән булса, Оешма җитәкчесе аны махсус төркемдә булу срогының бетү көнен күрсәтеп вакытлыча чыгара.

3.5.11. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балаларны, инвалид-балаларны сәламәтләндерү юнәлешендәге төркемнәргә кабул итү психологик-медик-педагогик комиссия нәтиҗәсе нигезендә тормышка ашырыла.

3.6. Баланы бер Оешмадан (беренчел Оешма) икенче Оешмага (кабул итүче) күчерү түбәндәге очракларда рөхсәт ителә:

- баланың ата-анасының (законлы вәкиленең) инициативасы буенча;

- беренчел Оешма эшчәнлеген туктаткан очракта, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру лицензиясен юкка чыгару;

- белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру лицензиясенең тәэсирен туктатканда.

3.6.1.Мәгариф идарәсе ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) язмача ризалыгы белән баланы күчерүне тәэмин итә.

3.6.2. Ата-аналарның гаризасы буенча баланы бер Оешмадан икенчесенә күчерү рөхсәт ителә. Баланы бер Оешмадан икенчесенә күчерү турында гариза Мәгариф идарәсенә бирелә.

Әгәр гариза бирүченең Оешмага чираттан тыш, беренче чиратта кабул ителүгә хокукы булса, гариза бирүчегә Мәгариф идарәсенә ташламаларны раслаучы документларны, шулай ук аларның күчермәләрен тапшырырга кирәк.

Системага күчерү турындагы гариза мәгълүматларын керткәндә ата-аналарның тиешле гаризаны бирү көне куела. Оешманы комплектлаганда баланы бер Оешмадан икенчесенә күчерү турындагы гариза гомуми чират тәртибендә карала. Ташламалы категориядәге гражданнар балалары баланы бер Оешмадан икенчесенә күчергәндә федераль законнар,Татарстан Республикасы законнары һәм башка законлы норматив актлар белән билгеләнгән ташламалардан файдаланалар.

3.6.3. Ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) (кызыксынучан ике якның да) гаризалары буенча төрле Оешмаларда бер яшь категориясендәге төркемгә йөрүче бер үк яшьтәге ике баланың урыннарын алмаштыру рөхсәт ителә. Алмаштыру буенча гариза район мәгариф бүлегенә ( идарәсенә) Оешманың урнашу урыны буенча бирелә.

3.6.4. Беренчел Оешманың эшчәнлеген туктату турында карар кабул иткәндә оештыручының тиешле боерыкнамә актында ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) күчерүгә язма килешүләре нигезендә балалар күчереләчәк кабул итүче Оешма яисә кабул итүче Оешмалар исемлеге күрсәтелә.

Оешманың эшчәнлеге туктатылган очракта тәрбияләнүчеләр чираттан тыш тәртиптә башка Оешмаларга күчереләләр.

3.6.5. 1 яшьтән 3 яшькә кадәр булган балалар өчен генә төркемнәр булган мәктәпкәчә учреждениеләргә йөрүче балалар өч яшь тулганнан соң Мәгариф идарәсе боерыгы буенча чираттан тыш тәртиптә башка Оешмаларга күчереләләр.

3.6.6. Баланы балалар бакчасыннан чыгарган очракта тиешле боекрыкны теркәгән көннән соң 1 эш көне дәвамында Оешма җитәкчесе Системада гариза “Чыгарылган” статусы бирә.

## IV. Муниципаль хезмәт бирүгә контрольлек итү тәртибе һәм формасы

4.1. Әлеге Административ регламент үтәлешенә агымдагы контрольне Мәгариф идарәсе җитәкчесе яки курьерлык итүче җитәкче урынбасары гамәлгә ашыра.

Мәгариф идарәсе боерыгы белән билгеләнгән вәкаләтле хезмәткәр закон нигезендә әлеге Административ регламент кушымталарын үтәүгә җаваплы.

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүгә агымдагы контроль Оешмаларның вәкаләтле хезмәткәрләре, җитәкчеләре тарафыннан әлеге Административ регламент кушымталарын үтәүне һәм башкаруны тикшерү юлы белән тормышка ашырыла.

4.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүгә агымдагы контроль даими нигездә тормышка ашырыла.

4.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгына һәм сыйфатына контроль гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуны тикшерү, ачыклау һәм бетерүне, гариза бирүчеләрнең муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы вазифаи затларның карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелгән мөрәҗәгатьләрен карауны, карар кабул итүне һәм җавап әзерләүне үз эченә ала.

4.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгына һәм сыйфатына тикшерүләр Мәгариф идарәсе актлары нигезендә тормышка ашырыла.

Тикшерүләр планлы (Мәгариф идарәсенең ярты еллык яки бер еллык эш планы нигезендә тормышка ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин.

4.5. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгына һәм сыйфатына планнан тыш тикшерүләр үткәрү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) элегрәк ачыкланган Административ регламент һәм муниципаль хезмәт күрсәтүгә таләпләр билгеләүче башка норматив-хокукый актлар таләпләрен бозуларны бетерүгә тикшерүләр уңаеннан;

2) гражданнарның муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы вазифаи затларның гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга шикаятьләр белән мөрәҗәгать итүләре.

4.6. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгына һәм сыйфатына тикшерүләр нәтиҗәсе акт белән рәсмиләштерелә, анда ачыкланган кимчелекләр һәм аларны бетерү буенча тәкъдимнәр күрсәтелә.

4.7. Контроль нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокуклары бозулы ачыкланган очракта гаепле затлар Россия Федерациясе законы нигезендә җавапка тартылалар.

4.8. Гариза бирүчеләр ягыннан муниципаль хезмәт күрсәтүгә контроль әлеге Административ регламент белән каралганча мәгълүмат алу юлы, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәткәндә карар кабул иткән вазифаи затның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирү юлы гамәлгә ашырыла.

4.9. Тикшерү барышында ачыкланган гражданнарның законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен бозулар хезмәт күрсәтүче учреждение тарафыннан бозу факты ачылган көннән алып 30 көннән артмаган срокта бетерелергә тиеш.

## V. **Гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазифаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерүе**

5.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазифаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерергә хаклы.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны теркәү срогын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу.

3) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары, муниципаль норматив-хокукый актлар, әлеге Административ регламент белән каралмаган документларны яки мәгълүматны яисә башка гамәлләрне таләп итү;

4) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясенең, норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары, муниципаль норматив-хокукый актлар, әлеге Административ регламент белән каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту, әгәр баш тарту нигезләре Россия Федерациясенең федераль законнары һәм алар нигезендә кабул ителгән башка норматив-хокукый актлары,Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив-хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар, әлеге Административ регламент тарафыннан каралмаган булса;

6) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәткәндә Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары, муниципаль норматив-хокукый актлар, әлеге Административ регламент белән каралмаганда, түләү таләп итү;

7) Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазифаи затының “Электрон балалар бакчасы”автоматлаштырылган мәгълүмат системасына гариза керткәндә җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы;

8) муниципаль хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срокларын һәм тәртибен бозу;

9) муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату, әгәр туктату сәбәпләре Россия Федерациясенең федераль законнары һәм алар нигезендә кабул ителгән башка норматив-хокукый актлар,Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив-хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар тарафыннан каралмаган булса.

10) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәткәндә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларны һәм мәгълүматны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда аларның булмаулары һәм (яки) дөрес булмаулары күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп итү , түбәндәге очраклардан кала:

а) беренче тапкыр муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргәннән соң, муниципаль хезмәт күрсәтүгә кагылышлы норматив-хокукый актлар таләпләрен үзгәртү;

б) муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризада һәм гариза бирүче тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтү өчен яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә кирәк булган документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканнан соң бирелгән һәм элек тапшырылган документлар комплектына кертелмәгән документларда хаталар булу;

в) документларның гамәлдә булу срогы чыгу яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен яисә муниципаль хезмәт күрсәткәндә кирәк булган документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканнан соң мәгълүматның үзгәрүе;

г) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә кирәк булган документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазифаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең хаталы яки хокукка каршы гамәлләрен (гамәл кылмавын) документаль раслаучы фактларның (билгеләрнең) ачыклануы, бу турыда муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесе имзасы белән гариза бирүчегә хәбәр ителә, шулай ук китергән уңайсызлыклар өчен гафу үтенәләр.

5.2. Гариза бирүчеләр шикаятьне нигезләү һәм карау өчен кирәк булган мәгълүматны һәм документларны алырга хокуклы.

5.3 Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазифаи затының, муниципаль хезмәткәрнең, муниципаль хезмәт

күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять муниципаль хезмәт күрсәтүче органга язма рәвештә кәгазьдә, электрон формада бирелә. Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесе тарафыннан кабул ителгән карарга шикаять югарыгы органга (әгәр ул булса) бирелә яисә ул булмаганда турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесе тарафыннан карала.

Шикаять почта аша, "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацион челтәреннән файдаланып, күпфункцияле үзәк, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның рәсми сайты, Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.4. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелгән муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазифаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең исеме;

2) гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы әгәр булса), яшәү урыны турында белешмә, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (әгәр булса) һәм почта адресы, аның буенча гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиеш;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазифаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерү турында белешмә;

4) гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазифаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән килешмәвен нигезләүче дәлилләр.

5.5 Гариза бирүче тарафыннан аның дәлилләрен раслаучы (алар булганда) документлар яисә аларның күчермәләре бирелергә мөмкин.

5.6. Шикаятьне карау өчен әһәмияткә ия булган документлар булмаса яки алар шикаятькә беркетелмәгән булса, карар дәлилләрне (аларны раслау өчен доккументлар тәкъдим ителмәгән) исәпкә алмыйча гына кабул ителә.

5.7. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органга яисә югарыгы органга (әгәр ул булса) кергән шикаять аны теркәгәннән соң унбиш эш көне дәвамында, әгәр муниципаль хезмәт күрсәтүче орган гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартса яки шикаять шундый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозып белдерелсә - аны теркәгәннән соң биш эш көне дәвамында каралырга тиеш.

Шикаятьне карау срогы киметелергә мөмкин булган очраклар Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

5.8.Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча муниципаль хезмәт күрсәтүче орган түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, "Электрон балалар бакчасы"автоматлаштырылган мәгълүмат системасына гариза керткәндә җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтү, гариза бирүчегә

акчаны кире кайтару формасында, әгәр акча алу Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары, муниципаль норматив-хокукый актлар,әлеге Административ регламент белән каралмаган булса;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта:

5.9 Карарны кабул иткән көннән соң килә торган көннән соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача формада һәм гариза бирүченең теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезләнгән җавап җибәрелә.

5.9.1. Шикаять канәгатьләндерерлек дип табылган очракта гариза бирүчегә җавапта муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган бозуларны тиз арада бетерү максатында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан тормышка ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китергән уңайсызлыклар өчен гафу үтенәләр һәм муниципаль хезмәт алу максатында гариза бирүчегә алга таба нәрсә эшләргә кирәклеге турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9.2. Шикаять канәгатьләндерерлек дип табылмаган очракта гариза бирүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында аргументлаштырылган аңлатма, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.10. Шикаятьне карау барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу составы билгеләре яки шикаятьне карау буенча вәкаләтләре булган вазифаи затның, хезмәткәрнең җинаять билгеләре ачыкланса, тиз арада булган материалларны прокуратура органнарына җибәрәләр.

Административ
регламентка 1нче кушымта

**ТР Чистай муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыручы муниципаль белем бирү оешмалары турында белешмә**

| № | Мәктәпкәчә белем бирү оешмасы исеме | Адрес | Рәсми сайт | Җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме | Учреждениенең эш режимы, җитәкченең кабул итү сәгатьләре |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Чистай муниципаль районының "Веселая карусель" "Катнаш | Чистай шәһәре, Чернышевский урамы, 167 Гнче | https://edu.tatar.ru/chistopol/org6231/page1152665.htm | Галләмова Фәридә Марс кызы | Дүшәмбедән җомгага кадәр 6.00-18.00кә кадәр |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | типтагы 1нче балалар бакчасы" МБДОУ | йорт,<br>8(84342)4-17-33 | | | сишәмбе, чәршәмб<br>14.00-17.00 |
| 2. | Чистай муниципаль районының "Радуга" "Катнаш типтагы 2нче балалар бакчасы" МБДОУ | Чистай шәһәре, Полющенков урамы, 12а<br>8(84342)4-71-77 | https://edu.tatar.ru/chistopol/page2123931.htm | Арсентьева Лариса Константиновна | Дүшәмбедән җомгага кадәр 6.00-18.00кә кадәр<br><br>сишәмбе 8.00-10.0<br>пәнҗешәмбе 16.00<br>18.00 |
| 3. | Чистай муниципаль районының "Кояшкай" "Катнаш типтагы 3нче балалар бакчасы" МБДОУ | Чистай шәһәре, К.Маркс ур., 62<br>8(84342)5-17-53 | https://edu.tatar.ru/chistopol/dou3_kojashkaj | Хәйруллина Эльвина Хәсән кызы | Дүшәмбедән җомгага кадәр 6.00-18.00кә кадәр<br><br>чәршәмбе 16.00-18.00 |
| 4. | Чистай муниципаль районының "4нче балалар бакчасы" МБДОУ | Чистай шәһәре, Ленин ур., 71 8(84342) 5-26-71, К.Либкнехт ур., 32 8(84342) 5-02-12 | https://edu.tatar.ru/chistopol/dou3_kojashkaj/dou4 | Шоетова Ирина Владимировна | Дүшәмбедән җомгага кадәр 6.00-18.00кә кадәр<br><br>сишәмбе,<br>пәнҗешәмбе 17.00<br>18.00 |
| 5. | Чистай муниципаль районының "Аленький цветочек" гомумүстерү тибындагы 5нче балалар бакчасы" МБДОУ | 422980<br>Чистай шәһәре, Н. Прибой ур., 8<br>5-90-40 | | Сафина Гүзәл Әхтәм кызы | Дүшәмбедән җомгага кадәр 6.00-18.00кә кадәр |
| 6. | Чистай муниципаль районының "Жемчужинка" гомумүстерү тибындагы 6нчы балалар бакчасы" МБДОУ | Чистай шәһәре, , Энгельс ур., 54<br>8(84342) 4-34-72 | https://edu.tatar.ru/chistopol/dou6_zhemchuzhinka | Захарова Ольга Рудольфовна | Дүшәмбедән җомгага кадәр 6.00-18.00кә кадәр<br><br>дүшәмбе 8.00-10.00<br>җомга 15.0-17.00 |
| 7. | Чистай муниципаль районының "7нче карау һәм сәламәтләндерү балалар бакчасы" МБДОУ | Чистай шәһәре, , К.Маркс ур.,54<br>8(84342) 5-20-05,<br>К.Маркс ур.,48<br>8(84342) 5-22-07 | https://edu.tatar.ru/chistopol/chistdou7 | Урманчиева Резидә Илтизәр кызы | Дүшәмбедән җомгага кадәр 6.00-18.00кә кадәр<br>дүшәмбе 7.45-9.00<br>пәнҗешәмбе 16.00<br>17.00 |
| 8. | Чистай муниципаль районының "Катнаш типтагы 8нче балалар бакчасы" МБДОУ | Чистай шәһәре, Энгельс ур.,56<br>8(84342) 4-34-15 | https://edu.tatar.ru/chistopol/dou8_dujmovochka | Дитарова Светлана Викторовна | Дүшәмбедән җомгага кадәр 6.00-18.00кә кадәр<br><br>көн саен 13.30-15.30<br>чәршәмбе 10.00-18.00 |
| 9. | Чистай муниципаль районының "Ласточка" "Катнаш типтагы 10 нчы балалар бакчасы" МБДОУ | Чистай шәһәре, К.Либкнехт ур.,48<br>8(84342) 5-21-22 | https://edu.tatar.ru/chistopol/dou10_lastochka | Нургалиева Фирдәүсә Миңневәли кызы | Дүшәмбедән җомгага кадәр 6.00-18.00кә кадәр<br><br>сишәмбе 12.00- |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 14.00 пәнҗешәмбе 15.30- 17.00 |
| 10. | Чистай муниципаль районының "Гомумүстерү тибындагы 11нче балалар бакчасы" | Чистай шәһәре, Бутлеров ур.,2в 8(84342) 5-48-51 | https://edu.tatar.ru/chistopol/dou11_orv | Молчанова Ирина Леонидовна | Дүшәмбедән җомгага кадәр 6.00-18.00кә кадәр сишәмбе 15.00-17.00 |
| 11. | Чистай муниципаль районының "13нче балалар бакчасы" МБДОУ | Чистай шәһәре, Крупская ур.,34 8(84342) 5-20-78 | https://edu.tatar.ru/chistopol/dou13 | Баринова Ольга Борисовна | Дүшәмбедән җомгага кадәр 6.00-18.00кә кадәр чәршәмбе, җомга 16.00-18.00 |
| 12. | Чистай муниципаль районының " Подсолнушек" 14нче карау һәм сәламәтләндерү балалар бакчасы" МБДОУ | Чистай шәһәре, Тукай ур.,54 8(84342) 5-12-04 | https://edu.tatar.ru/chistopol/dou14_podsolnushek | Симонова Ольга Борисовна | Дүшәмбедән җомгага кадәр 6.00-18.00кә кадәр сишәмбе 14.00-17.00 |
| 13. | Чистай муниципаль районының " Виктория" гомумүстерү тибындагы 16нчы балалар бакчасы" МБДОУ | Чистай шәһәре, Мебельная ур.,4 8(84342) 5-83-54 | https://edu.tatar.ru/chistopol/dou16_viktoriya/page2042659.htm | Тишина Александра Владимировна | Дүшәмбедән җомгага кадәр 6.00-18.00 Пәнҗешәмбе 16.00-18.00 |
| 14. | Чистай муниципаль районының "Катнаш типтагы 17нче балалар бакчасы" МБДОУ | Чистай шәһәре, Җиңүнең 40 еллыгы ур., 37 8(84342) 4-00-93 | https://edu.tatar.ru/chistopol/dou17 | Батыршина Резидә Рушан кызы | Дүшәмбедән җомгага кадәр 6.00-18.00кә кадәр сишәмбе 9.00-11.00 пәнҗешәмбе 16.00- 17.00 |
| 15. | Чистай муниципаль районының "Колобок" 18нче балалар бакчасы" МБДОУ | Чистай шәһәре, Текә Тау пос., Камская ур.,2 8(84342) 5-70-27 | https://edu.tatar.ru/chistopol/dou18 | Пузырева Алсу Гомәр кызы | Дүшәмбедән җомгага кадәр 6.00-18.00кә кадәр сишәмбе 15.00-17.00 |
| 16. | Чистай муниципаль районының "19 нчы балалар бакчасы" МБДОУ | Чистай шәһәре, Тукай ур,54 8(84342) 5-10-81 | https://edu.tatar.ru/chistopoд/dou19 | Сөнгатуллина Алсу Зиннур кызы | Дүшәмбедән җомгага кадәр 6.00-18.00кә кадәр дүшәмбе 15.00-18.00 чәршәмбе 8.00-12.00 |
| 17. | Чистай муниципаль районының "Мозаика" гомумүстерү тибындагы 20нче балалар бакчасы" МАДОУ | Чистай шәһәре, Ак.Королёв ур., 5а 8(84342) 4-72-78, 4-72-36 | https://edu.tatar.ru/chistopol/dou20_mozaika | Зиновьева Жанна Евгеньевна | Дүшәмбедән җомгага кадәр 6.00-18.00кә кадәр дүшәмбе 16.00-18.00 |
| 18. | Чистай муниципаль районының "21нче балалар бакчасы" | Чистай шәһәре, Мир ур.,14 8(84342) 5-81-86 | https://edu.tatar.ru/chistopol/dou21 | Богданова Татьяна Юрьевна | Дүшәмбедән җомгага кадәр 6.00-18.00кә кадәр |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | МБДОУ | | | | сишәмбе 16.00-18.00 |
| 19. | Чистай муниципаль районының "Катнаш типтагы 22нче балалар бакчасы" МБДОУ « | Чистай шәһәре, Красноармейская ур., 64а 8(84342)5-06-69, Л.Толстой ур.,90 8(84342) 5-08-08 | https://edu.tatar.ru/chistopol/dou22_komb | Чередова Ольга Анатольевна | Дүшәмбедән җомгага кадәр 6.00-18.00кә кадәр сишәмбе 15.00-17.00 |
| 20. | Чистай муниципаль районының " Сказка" гомумүстерү тибындагы 23нче балалар бакчасы" МБДОУ | Чистай шәһәре, Ф.Энгельс ур.,119,а 8(84342) 9-42-69 | https://edu.tatar.ru/chistopol/dou23_skazka | Агафонова Таисия Александровна | Дүшәмбедән җомгага кадәр 6.00-18.00кә кадәр Сишәмбе 8.00-10.00 Пәнҗешәмбе 15.00-18.00 |
| 21. | Чистай муниципаль районының "Йолдызкай" 25нче балалар бакчасы" МБДОУ | Чистай шәһәре, Җиңүнең 40 еллыгы ур., 40 8(84342) 4-00-88 | https://edu.tatar.ru/chistopol/dou25_joldyzkaj | Хәмзина Гүзәл Зәйнулла кызы | Дүшәмбедән җомгага кадәр 6.00-18.00кә кадәр дүшәмбе 9.00-11.00 чәршәмбе 15.00-17.00 |
| 22. | Чистай муниципаль районының " Теремок" гомумүстерү тибындагы 27нче балалар бакчасы" МБДОУ | Чистай шәһәре, Җиңүнең 40 еллыгы ур., 47 8(84342) 4-01-98 | https://edu.tatar.ru/chistopol/dou27_teremok | Вәлиуллина Гүзәл Наил кызы | Дүшәмбедән җомгага кадәр 6.00-18.00кә кадәр дүшәмбе 15.00-17.00 |
| 23. | Чистай муниципаль районының "Катнаш типтагы 28нче балалар бакчасы" МБДОУ | Чистай шәһәре, Энгельс ур.,78 8(84342) 4-31-16 | https://edu.tatar.ru/chistopol/dou28_komb | Лоскутова Нина Михайловна | Дүшәмбедән җомгага кадәр 6.00-18.00кә кадәр сишәмбе 8.00-10.00 пәнҗешәмбе 15.00-17.00 |
| 24. | Чистай муниципаль районының "Катнаш типтагы 26нчы балалар бакчасы" МБДОУ | Чистай шәһәре, Энгельс ур., 116 9-48-40 | https://edu.tatar.ru/chistopol/dou_26 | Ильина Людмила Николаевна | Дүшәмбедән җомгага кадәр 6.00-18.00кә кадәр сишәмбе 8.00-17.00 җомга 8.00-12.00 |
| 25. | Чистай муниципаль районының "Гаделшә балалар бакчасы" МБДОУ | 422964, Гаделшә авылы, Школьная ур.,4 б | https://edu.tatar.ru/chistopol/tat-adelshino/dou | Вәлиуллина Рамилә Әнвәр кызы | Дүшәмбедән җомгага кадәр 7.00-16.00 Сишәмбе 14.00-16.00 Пәнҗешәмбе 7.00-9.00 |
| 26. | Чистай муниципаль районының "Александровка балалар бакчасы" МБДОУ | 422965, Александровка авылы, Школьная ур., 14 8(84342) 3-74-80 | https://edu.tatar.ru/chistopol/aleksandrovka/dou | Зәйнуллина Флюра Рамазан кызы | Дүшәмбедән җомгага кадәр 7.00-16.00 Сишәмбе 14.00- |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 16.00<br>Пәнҗешәмбе 7.00<br>9.00 |
| 27. | Чистай муниципаль районының “Олы Талкыш балалар бакчасы” МБДОУ | 422967<br>Олы Талкыш авылы, Пришкольная ур., 2а | https://edu.tatar.ru/chistopol/b-tolkish/dou | Никитин Александр Александрович | Дүшәмбедән җомгага кадәр 7.30-16.30<br><br>Дүшәмбе 8.00-11.0<br>Чәршәмбе 8.00-11.00<br>Җомга 8.00-11.00 |
| 28. | Чистай муниципаль районының “Радость” Бахта балалар бакчасы” МБДОУ | 422960 Бахта авылы, Широкая ур., 4б<br>8(84342) 3-23-39 | https://edu.tatar.ru/chistopol/tat-adelshino/dou/bahta/dou | Филиппова Галина Анатольевна | Дүшәмбедән җомгага кадәр 7.30-16.30<br><br>Сишәмбе 8.00-12.00<br>Пәнҗешәмбе 13.00-16.30 |
| 29. | Чистай муниципаль районының “Кубасс балалар бакчасы” МБДОУ | 422954 Кубассы, Озёрная ур.,14<br>8(84342) 3-15-25 | https://edu.tatar.ru/chistopol/kubassy/dou | Сабирҗанова Дания Забих кызы | Дүшәмбедән җомгага кадәр 8.00-17.00<br><br>Дүшәмбе 8.00-14.0 |
| 30. | Чистай муниципаль районының “Яуширмә балалар бакчасы” МБДОУ МБДОУ | 422955,<br>Яуширмә авылы, Г. Исхакый ур.,4 | https://edu.tatar.ru/chistopol/kutlushkino/dou | Смурыгина Регина Юрьевна | Дүшәмбедән җомгага кадәр 7.30-16.30<br><br>Сишәмбе 8.00-10.00<br>Пәнҗешәмбе 14.00-16.00 |
| 31. | Чистай муниципаль районының “Мөслим балалар бакчасы” МБДОУ | 422960, Мөслим авылы, Школьная ур., 11<br>8(84342) 3-23-99 | https://edu.tatar.ru/chistopol/luch/dou/muslyumkino/dou | Хәйретдинова Лилия Галимҗан кызы | Дүшәмбедән җомгага кадәр 7.30-16.30<br><br>Сишәмбе 14.00-16.00<br>Пәнҗешәмбе 8.00<br>10.00 |
| 32. | Чистай муниципаль районының “Түбән Кондрата балалар бакчасы” МБДОУ | 422923, Түбән Кондрата, 1 Май ур., 7а<br>8(84342) 3-07-00 | https://edu.tatar.ru/chistopol/n-kondata/dou | Родионова Оксана Дмитриевна | Дүшәмбедән җомгага кадәр 7.30-16.30<br><br>Сишәмбе 8.00-9.00 |
| 33. | Чистай муниципаль районының “Иске Роман балалар бакчасы” МБДОУ | 422970, Иске Роман авылы, Центральная ур., 30б | https://edu.tatar.ru/chistopol/st-romashkino/dou | Дәүләтшина Гөлнара Илфат кызы | Дүшәмбедән җомгага кадәр 7.30-16.30<br><br>Сишәмбе 14.30-16.30<br>Җомга 14.30-16.30 |
| 34. | Чистай муниципаль районының “Татар Ялтаны балалар бакчасы” МБДОУ | 422975, Татар Ялтаны, Садовая ур., 25<br>8(84342) 3-47-36 | https://edu.tatar.ru/chistopol/tat-bagana/dou/page240226.htm | Нармурадова Гөлнур Шаман кызы | Дүшәмбедән җомгага кадәр 7.30-16.30<br><br>Пәнҗешәмбе 15.00-16.30 |
| 35. | Чистай муниципаль районының “Татар Банагалысы балалар бакчасы” МБДОУ | 422963, Татар Баганалысы авылы, Советская ур.,18 а<br>8(84342) 3-62-61 | https://edu.tatar.ru/chistopol/tat-bagana/dou | Нуруллина Фирдәүсә Эфраил кызы | Дүшәмбедән җомгага кадәр 7.30-16.30<br><br>Пәнҗешәмбе 15.00<br>16.30 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 36. | Чистай муниципаль районының "Татар Талкышы балалар бакчасы" МБДОУ | 422961, Татар Талкышы, Советская ур., 5<br>8(84342) 3-32-14 | https://edu.tatar.ru/chistopol/st-romashkino/dou/tat-tolkish/dou | Гыймадиева Сәкинә Зөфәр кызы | Дүшәмбедән җомгага кадәр 7.30-16.30<br><br>Пәнҗешәмбе 15.00-16.30 |
| 37. | Чистай муниципаль районының "Четырчы балалар бакчасы" МБДОУ | 422964 Четырчы авылы, Зелёная ур., 13 | https://edu.tatar.ru/chistopol/chetyrchi/dou | Әхмәтҗанова Гузәл Рафис кызы | Дүшәмбедән җомгага кадәр 7.30-16.30<br><br>Сишәмбе 8.30-10.3 |
| 38. | Чистай муниципаль районының " Золотая рыбка"Кызыл Яр балалар бакчасы" МБДОУ | 422967, Красный Яр авылы, Пришкольная ур.,37<br>8(84342) 3-37-69 | https://edu.tatar.ru/chistopol/kr-yar/dou | Ильина Марина Петровна | Дүшәмбедән җомгага кадәр 7.30-16.30<br><br>Сишәмбе 14.00-16.00<br>Пәнҗешәмбе 10.00 12.00 |
| 39. | Чистай муниципаль районының "11 нче Каргалы балалар бакчасы" МБДОУ | 422971, Каргалы авылы, Советская урамы, 37<br>8(84342) 9-22-95 | https://edu.tatar.ru/chistopol/kargali/dou11 | Әхмәтҗанова Рәмзия Илгизәр кызы | Дүшәмбедән җомгага кадәр 6.30-18.30<br><br>Дүшәмбе 9.00-10.0<br>Пәнҗешәмбе 15.00 16.00 |
| 40. | Чистай муниципаль районының "15нче Каргалы балалар бакчасы" МБДОУ | 422971<br>Каргалы авылы, Советская урамы,15 | https://edu.tatar.ru/chistopol/kargali/dou15 | Гыймадиева Гөлия Гобәйдулла кызы | Дүшәмбедән җомгага кадәр 6.30-18.30<br><br>Дүшәмбе 8.00-10.0 |
| 41. | Чистай муниципаль районының "Татар Сарсазы балалар бакчасы" МБДОУ | 422970<br>Татар Сарсазы авылы, Зеленая урамы, 25 | https://edu.tatar.ru/chistopol/tat-sarsazy/dou | Садыйкова Гөлнара Хәлим кызы | Дүшәмбедән җомгага кадәр 6.00-18.00<br><br>Сишәмбе, пәнҗешәмбе 16.00-17.30 |
| 42. | Чистай муниципаль районының "Чистай Выселкасы балалар бакчасы" МБДОУ | 422958, Чистай Выселкасы, Гагарин урамы, 65 б<br>8(84342) 3-94-89 | https://edu.tatar.ru/chistopol/page240226.htm/chist-vyselki/dou | Стеклыщикова Юлия Николаевна | Дүшәмбедән җомгага кадәр 6.00-18.00<br><br>Дүшәмбе 8.00-18.0<br>Чәршәмбе 14.00-17.00 |
| 43. | Чистай муниципаль районының "Луч балалар бакчасы" МБДОУ | 422952, Луч поселогы, Җиңү урамы 15<br>8(84342) 4-81-02 | https://edu.tatar.ru/chistopol/kr-yar/dou/luch/dou | Вәлиева Зөлфия Әнвәр кызы | Дүшәмбедән җомгага кадәр 6.00-18.00<br><br>Сишәмбе 7.45-8.45<br>Пәнҗешәмбе 16.30 17.30 |
| 44. | Чистай муниципаль районының "Йолдыз балалар бакчасы" МБДОУ МБДОУ « | 422980, Йолдыз поселогы, Комсомольская ур., 1а.<br>8(84342) 3-43-37 | https://edu.tatar.ru/chistopol/yulduz/dou | Волякова Татьяна Александровна | Дүшәмбедән җомгага кадәр 6.30-18.30<br><br>Сишәмбе 15.00-17.00 |
| 45. | ТР Чистай муниципаль районының "Кече Талкыш балалар бакчасы" МБДОУ | 422980, Кече Талкыш авылы | https://edu.tatar.ru/chistopol/dou28_komb/m-tolkish/dou | Шәрипова Светлана Юрьевна | Дүшәмбедән җомгага кадәр 7.00-16.00<br><br>Дүшәмбе 8.00-9.00<br>Җомга 15.00-16.00 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 46. | ТР Чистай муниципаль районының “Данауровка башлангыч мәктәбе - балалар бакчасы” МОУ | 422950, Данауровка авылы | | Нигъмәтуллина Наилә Галимҗан кызы | Дүшәмбедән җомгага кадәр 6.00-18.00<br><br>Чәршәмбе 16.00-17.00 |

Административ регламентка
2нче кушымта

Персональ мәгълүматларны автоматлаштырылган эшкәртүгә РИЗАЛАШУ

Гариза

Мин,______________________________________________________________,
*(Ф.И.О.)*

_________________________________________________________________ ,
*теркәлү адресы*

_________________________________________________________________,
*(шәхесне раслаучы документ төре, сериясе, номеры, кем биргән һәм кайчан бирелгән)*

Татарстан Республикасының мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына йөрүче һәм кабул ителү өчен чиратта торучы балаларның мәгълүматлар базасын формалаштыру максатында персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирәм:

_________________________________________________________________,
*(Ф.И.О., ата-ананың берсенең (законлы вәкиленең) паспорт мәгълүматлары*

_________________________________________________________________,
*(Ф.И.О., туган көне, баланың туу турындагы таныклыгы мәгълүматлары*

_________________________________________________________________,
*(фактта яшәү адресы, баланың сәламәтлеге турында белешмә)*

_________________________________________________________________,
*(мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенә ташламалы кабул итүгә хокук булу-булмау)*

документаль һәм электрон формаларда гамәлгә ашыру мөмкинлеге белән автоматлаштырылган һәм автоматлаштырылмаган ысул белән персональ мәгълүматларны җыю, системага салу, туплау, саклау, ачыклау (үзгәрешләрне яңарту), файдалану, тарату (шул исәптән тапшыру), үзенчәлекләрен бетерү, юкка чыгару.


Әлеге килешү дәвамында гамәлдә: ___________________________.


Әлеге килешү минем тарафтан язма рәвештә кире алынырга мөмкин.Әлеге килешүне гамәлдә булу срогы беткәнче кире алган очракта үз персональ мәгълүматларымны эшкәртү туктатылуның нинди нәтиҗәгә китерүе турында кисәтелдем.

Вакыты ______________

Гариза бирүченеә шәхси имзасы__________(_____________) *(имзаны тутырып язу)*

Административ регламентка
3нче кушымта




Телəгəн МБОда урын бармы?
Әйе
Юк->
Гариза бирүченең башка МБОга ризалашуы
Юк
<-- Әйе
МБОга юллама бирү
Әйе
Хезмəт күрсəтелде
Гариза бирүче үзе телəгəн МБОга чират көтəргə ризамы?